وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№6 (123). 10 февраль 2012 / 18-раббигыль-әүвәл-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



*Индус Таһиров:* "Һәр революциягә альтернатива бар"

▷2◁



Стрессмы, иман тынычлыгымы?

▷3◁



Барак Обаманың әбисен Аллаһ саклады

▷4◁

## ЯҢАЛЫКЛАР

### ХӘЗЕРГЕ ҖӘМГЫЯТЬТӘ ТОЛЕРАНТЛЫК МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ

3 февраль көнне Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәге казые Марат хәзрәт Мәрданшин Ютазы районының Урыссу посёлыгы татар гимназиясе укучылары белән очрашты. Очрашу "Хәзерге җәмгыятьтә толерантлык мөнәсәбәтләре" дигән темага багышланды. Марат хәзрәт укучыларны очрашу барышында әңгәмәдәшеңне дикъкать белән тыңларга, бер-береңне ихтирам итәргә чакырды. Толерантлык - халыклар арасында гына түгел, социаль төркемнәрдә, башка мәдәният, милләт, дин һәм социаль төркемнән булган кешеләр белән уртак тел табарга да ярдәм итә.

### БӨГЕЛМӘ РАЙОНЫ ИМАМНАРЫ БЕЛЕМНӘРЕН КҮТӘРӘ

6 февральдән 16 февральгә кадәр Бөгелмә районы имамнары РИУ каршындагы Имамнарның квалификациясен күтәрү үзәгендә белемнәрен арттыра. Курсларда Коръән, тәҗвид, фикъһе, ислам тәгълиматы, имам вазифалары һәм психология фәннәре буенча уннан артык имам гыйлем ала. ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан оештырылган әлеге курсларда 72 сәгать каралган.

### МӨФТИ - ТАТАРСТАН РАЙОННАРЫНДА

4 февраль көнне ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Илдус хәзрәт Фәиз Әлмәт, Чистай һәм Алексеевск районнарында булып, мөселманнар белән очрашулар үткәрде.

6 февральдә мөфти Апас, Буа, Тәтеш, Чүпрәле районнарында җирле имамнар һәм җитәкчеләр белән очрашты. Очрашулар вакытында И.Фәиз мөселманнарны Мәүлид бәйрәме белән котлады, салаватлар укыды, халыкны кызыксындырган сорауларга җавап бирде. Шулай ук ул дүрт имаммөхтәсибкә шәһадәтнамәләр тапшырды. Әлеге шәһадәтнамәләр бер елга бирелә.

7 февральдә Диния нәзарәте рәисе Кайбыч, Кама Тамагы, Югары Ослан һәм Яшел үзән районнары имамнары белән очрашты. Әлеге чарада муниципаль районнарның һәм җирле авыл советларының җитәкчеләре дә катнашты.

Исегезгә төшерәбез: мөфтинең республика районнары буенча ике атналык эшлекле сәфәре Коръән елы һәм Мәүлид ае кысаларында оештырыла. Ике атна дәвамында мөфти Татарстанның барлык районнарында булырга, җирле имамнар һәм районнардагы мәхәллә мөселманнары белән очрашырга ниятли. Очрашу барышында район мөселманнарын борчыган мәсьәләләр турында сөйләшүләр, Диния нәзарәтенең планнары турында фикер алышулар булыр дип көтелә.

### МӨФТИ ТАТАРСТАННЫҢ РОССИЯДӘГЕ ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛЛЕГЕНДӘ БУЛДЫ

8 февраль көнне ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт Фәиз Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге вәкаләтле вәкиллегендә булды. Мөфти биредә вәкаләтле вәкилнең халыкара һәм икътисад эшләре буенча урынбасары Булат Миңнуллин һәм вәкаләтле вәкил урынбасары Алмаз Фәйзуллин белән очрашты. Очрашуда шулай ук мөфтиятнең дәгъват һәм мәгълүмат бүлеге мөдире Ришат Хәмидуллин һәм халыкара эшләр бүлеге мөдире Хәбибулла Нәфисуллин катнашты.

***Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды***

# МӨСЕЛМАННАРНЫ БЕРЛӘШТЕРҮ - ТӨП МАКСАТЫБЫЗ

**Ислам - бердәмлеккә һәм кардәшлеккә, бер-береңә мәрхәмәтле булырга, рухи ныклыкка, туганлыкка чакыручы дин. Чын мөселманның күңелендә мәкерле хисләргә, дошманлыкка урын булмый. Иман ныклыгы, сәламәт акыл, рухи көч аркылы мөселманнар бер-берсенә һәрвакыт ярдәм итеп, бердәмләшеп яши. Мөселманнарны берләштерү - дин әһелләре каршында торган бурыч кына түгел, һәр мөэмин-мөселманның намус эше булып тора.**

Изге Коръәни-Кәримдә: "Ий мөэминнәр! Барчагыз да бер булып, Аллаһның арканына (Коръәнгә, Ислам диненә) тотыныгыз, таркалып аерылмагыз. Сез бер-берегезгә дошман идегез, Ул сезнең күңелләрегезне берләштерде. Аның нигъмәте аркасында кардәшләр булдыгыз вә сез астында ут янып торган упкынның кырыенда идегез, аннан сезне Ул коткарды. Аллаһ сезгә аятьләрен менә шулай ап-ачык итеп аңлата. Шаять, тугры юлга ирешерсез. Сездән шундый бер өммәт булырга тиеш ки, алар һәркемне аерым эшләргә, игелеккә өндәрләр, яманлыктан ваз кичәргә чакырырлар. Менә шундыйлар морадларына (бәхеткә) ирешкән кешеләр булыр", - диелә ("әл-Гыймран" сүрәсе, 103-104 нче аятьләр).

Мөселманнарның бердәмлеге бер-берсе белән үзара аңлашуда, хәерхаһлы һәм ихтирамлы булуда чагыла.

Тарихта билгеле булганча, гыйлем иңдергәннән соң да, уртак фикергә килә алмыйча, каршылык күрсәтүче, таркалган кавемнәр булган. Һәм алар хәзер дә бар. Аллаһы Сөбхәнәһү вә Тәгалә тарафыннан андыйлар гафу кылынмый. Шуңа да шушы дөньяда яшәгәндә, бердәм булып, бергәләшеп динебезне ныгытырга кирәк.

Мөселманнарның бердәмлеге кардәшлекнең төп күрсәткече булып тора. Әшнәлек, бер-береңә хәерхаһлы булу бердәмлектә чагыла. "Мөселманнар үзара кардәш. Шулай булгач, кардәшләрнең арасын җайласагыз вә Аллаһтан (җәзасыннан) курыксагыз, ярлыканырсыз, Аның рәхмәтләренә ирешерсез" ("Хуҗурат (Бүлмәләр)" сүрәсе, 10 нчы аять).

Үзең һәм башкалар арасын гына түгел, җәмгыятебезне нигезеннән алып үзгәртү, кешеләр арасында кардәшлек кебек изге мөнәсәбәтләр урнаштыру - менә безнең алдыбызда торган изге бурычыбыз.

Сөннәтебез дә даими рәвештә мөселманнарны бердәмлеккә чакырып тора: "Мөселманнар - кардәшләр. Кем үзенең кардәшенә булыша, ярдәм итә, аңа Аллаһы Тәгалә дә булышыр", - диелә хәдистә.

Бүгенге көндә республикабыз имамнары, дин әһелләре каршында шушы зур бурыч тора - мөселманнарны берләштерү бурычы. Бу исә мәхәллә халкын яисә мәдрәсәдә гыйлем алучы шәкертләрне генә берләштерү түгел, бу - күпкә җаваплырак. Барлык мөселман кардәшләребезнең күңелләрен, телләрен, рухларын бер кыйблага көйләү. Төрле мәзһәбләргә аерылуны бетереп, Коръән кушканча яшәү, Аллаһы Сөбхәнәһү вә Тәгалә тыйганнардан тыелып, фарыз гамәлләрен үтәп, Кыямәт көнендә үзебезнең кылган гамәлләребездән оялмаслык булып яшәү. Үзеңнең гамәлләрең өчен генә түгел, мөселман кардәшләреңнең гамәлләре өчен дә кызармаслык итеп яшәү. Ә моңа ирешү бер караганда авыр да, шул ук вакытта җиңел дә.

Үзеңә теләгәнне кардәшеңә дә теләү, кулларыбызны догага күтәргәндә, мөселман өммәтенең ныклыгын кайгырту, кардәшеңә килгән борчуны үзең аша үткәрә алу, бер-береңә ихтирамлылык, сабырлык, теләктәшлек аша килә бу. Боларны искә алганда, бер караганда, бик авыр кебек тоелса да, икенче караганда, бик җиңел дә. Җиңел - иманы нык кешеләргә. Алар үзләренең рухларын игелекле гамәлләр кылып, шушы санап үтелгәннәрне даими кылып чыныктырганнар. Һәм алар моны игелек кылам дип түгел, ә "бары тик шулай гына эшләп була", ягъни бердәнбер хакыйкый юл буларак, ихлас күңелдән кылалар.

Әлеге "хакыйкый юл"ны һәрбер мөселман үзенә үрнәк итеп алса, "ми-н"леgennән бигрәк, "без" дигән өммәт турында уйласа, мөселман өммәте генә түгел, күп милләтле, төрле диндәге, төрле расалы җәмгыятебез дә күзгә күренеп үзгәрер иде. Мөселманнарга ихтирам артыр иде, халык дингә ихластан тартылыр иде.

Без - мөселманнар, барыбыз да бертигез. Шуңа да, үзебезне икенче берәүдән өстен куймыйча, теләктәшлектә яшәү - безнең бурычыбыз. Якындагы мөселман кардәшләребезне яклап, еракътагылары белән җылы мөнәсәбәтләрне саклап яшәргә кирәк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) дә мөселманнар арасындагы дошманлыкка, аерылышуга, таркалуга каршы чыга.

Үзенең бер хәдисендә пәйгамбәребез (сгв): "Бер-берегезгә карата мәкерле хисләр кормагыз, көнләшмәгез, бер-берегездән баш тартмагыз, бер-берегезгә кардәш булыгыз", - ди.

Барлык кардәшләребез өчен дә хак юлга чыгуны сорыйк. Шул тапкан кыйблабыздан тайпылмыйча, Аллаһ ризалыгына ирешергә, мөселман кардәшләребез белән бер өммәт булып яшәргә насыйп булса иде. Шул вакытта гына яшәү мәгънәсен табарбыз һәм ике дөнья бәхетенә ирешербез.

***Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ***

# ВЛАДИМИР ПУТИН
## дини конфессия вәкилләре белән очрашты

**8 февраль көнне Владимир Путин, Россия президенты постына кандидатларның берсе буларак, илебезнең төп конфессия вәкилләре белән очрашты.**




Мөселман дини оешмаларыннан очрашуда Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте рәисе, мөфти Тәлгат хәзрәт Таҗетдин, Россия мөфтиләре шурасы рәисе Равил хәзрәт Гайнетдин, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт Фәиз, Төньяк Кавказ мөселманнарының Координацион үзәге башлыгы Исмәгыйль хаҗи Бердыев, Россия ислам килешүе ассоциациясе рәисе Мөхәммәт хәзрәт Рәхимов катнашты.

Очрашуда Россия Хөкүмәте рәисе билгеләп узганча, дәүләтнең төрле конфессия вәкилләре белән бергәлектә эшләвенең максаты - аларның гаиләләрне, мораль кыйммәтләрне үстерүгә булган ярдәмен тоеп, булган проблемалардан котылу нияте белән.

Моннан тыш, В.Путин ассызыклаганча, илебездә дини эшчәнлек алып баруга тулы ирек бирелгән һәм әлеге ирек барлык дин вәкилләре өчен дә бертигез. Ул шулай ук дини оешмалар юлыга торган проблемаларны да атап узды, мисал өчен, шундыйлардан, Путин сүзләре белән әйткәндә, "чёрствость, излишнее администрирование или даже мздоимство" кебекләрен, ул, аерым бер конкрет дин белән мөнәсәбәттә генә түгел, ә илнең гомуми проблемалары белән бәйләнештә карады.

РФ Премьер-министры дәүләтнең совет власте елларында җыелган "әҗәт"ен кайтарудагы тырышлыклары турында да әйтте. Православ чиркәвенә караган күп санлы биналарның халыкка кайтарылуы турында сөйләп, Путин: "Башка конфессияләр дә, бүтән дини оешмалар да, дәүләтнең аларны читләтеп үтүеннән зарлана алмаслар, - диде. - Мәсәлән, Россия тарихында мөселманнарга мәчетләрнең бу күләмдә моңа кадәр бер тапкыр да кайтканы булмады. Аларның исәбе йөзләп, меңләп бара".

Россия президентына кандидат шулай ук югары белемгә дә игътибарын юнәлтте. "Дәүләт карамагындагы һәм дини оешма катнашындагысы белән төзелгән югары уку йорты һәм мәктәпләрнең дәрәҗәсен тигезләргә, һәм арендага алу, һәм бюджет чараларына ия булуга караган, һәм уку-укыту стандартларына кергән фәннәрнең укытучыларына хезмәт хакы түләү мәсьәләләренә бәйле принципиаль сорауны ахырына кадәр чишәргә кирәк", - дип саный В.Путин. Ул басым ясап узганча, бу өлкәдә дискриминация булырга тиеш түгел.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# 1917 елга кадәрге татар мәдрәсәләреннән өчәр-дүртәр тел белеп чыгу – гадәти хәл булган!

## (Тел турында уйланулар...)

***Фән-техника зур тизлек белән үскән, радио-телевидение, интернет аша кирәк һәм кирәкмәс мәгълүмат ташкыны агылган һәм алардан күбесенчә тормышның тискәре яклары күрсәтелгән бер заманда шул тормышта югалып калмаслык, үз урынын табарлык нык ихтыяр көченә ия булган, белемле һәм әхлаклы буынны ничек тәрбияләргә?***

Тәрбия нәрсәгә нигезләнергә тиеш? Моңа җавап бер: милли традицияләргә, буыннан-буынга килгән әхлакый кыйммәтләргә. Балада әхлакый кыйммәтләрнең бары тик ана теле, ата-ана тәрбиясе аша гына формалашуы бәхәссез. Туган җирнең - үзенең кечкенә Ватанының тарихын белеп, казанышлары белән горурланып, күренекле кешеләренә сокланып, үзе дә шулар кебек булырга омтылып үскән бала ил язмышы белән кызыксынып яши, аның патриоты булырга тырыша.

Ана теле - зур хәзинә ул, дибез. Бүген безнең телебез ни хәлдә? Аның тәрбия процессында тоткан урыны ни дәрәҗәдә? Мин бу язмамда күп еллар дәвамында үзем туплаган кайбер фикерләр турында язарга телим.

Мин егерме елдан артык мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укытам. Элеккерәк еллар укучылары белән бүгенгеләре арасында аерма сизелерлек. Бүген ана телебезнең бөтен нечкәлекләрен тоеп, язучы теленең образлылыгына, аһәңлелегенә мөкиббән китеп укучы балалар аз инде. Повесть һәм романның "эченә" кереп китеп, геройлар язмышы белән яшәп, әсәрнең тизрәк ахырына җитәргә теләп укучылар да күп түгел. Ә инде аерым язучының иҗатын тулаем күз алдына китерүче, аның яңа әсәрләрен көтеп алучылар бармак белән санарлык. Ни өчен шундый хәл? Сәбәпләрен эзләп карыйк.



Бүген телевидение милләтне телдән биздермәс өчен эшли кебек. Ләкин татарча тапшыруларның зәвык ягыннан түбән булуын да танырга кирәктер. Өч көнлек җырлар да, сәнгатьлелек дәрәҗәсе шактый түбән тапшырулар да, юк-бар мәзәккә корылган шоу-программалар да халыкны телдән, әдәбияттан, алай гына да түгел, милләтең белән горурланудан да биздереп бара.

Шул ук телевидение аша барган үтерешсугыш-суеш фильмнары да балаларда кансызлык, читләр кайгы-сагышына битарафлылык тәрбияли. Бүгенге укучының күңелен Акъәби сагышы да, Бибинур фаҗигасе дә сызландырмый инде.

Эшли башлаган елларымда мәктәпләргә еш кына язучылар, шагыйрьләр килә иде. "Тере шагыйрь" күргән укучыларым хәзер дә шул бәйрәмне искә ала. Соңгы елларда аларның, мәктәпләргә килеп, балалар белән очрашулары ифрат сирәгәйде. Дөрес, килә алмауларының да аерым сәбәпләре бардыр. Ләкин бит киләчәктә һәм бүгенге көндә әдип әсәрләрен укучылар мәктәптә тәрбияләнә!

Әдәбият укылсын өчен, әлбәттә, телгә игътибар булырга тиеш. Кояш астына һәр халык үзенә урын даулый. Җир йөзендәге орыш-талашларның, сугышларның бер сәбәбе шул тел бит инде!

Һәр халык үз тарихын, үз рухын, җырмоңын сакламакчы, аны яңа буыннарга тапшырмакчы. Ә бу бары тик тел ярдәмендә башкарыла. Димәк, милләтебезне саклыйбыз дибез икән, иң әүвәл телне саклау зарур. Әгәр дә кайсыдыр буын телгә игътибарсыз карый башлый икән, моның бер сәбәбен алдагы буыннардан да эзләргә кирәктер. Аяныч булса да искә төшерик: моннан утыз-кырык еллар элек авылдан шәһәргә килгән сәләтле күпме татар яшьләре, русча белмәү сәбәпле, югары уку йортларына керә алмады. Хәзерге чорның яңарак гаилә корып балалар үстерә башлаган буыны - шул заман яшьләренең дәвамы. Аларның миенә татар телен белергә кирәкми, дигән фикер сеңдерелгән, һәм шуны алар балалары башына сеңдерәләр. Ә бит теге еллардан үзгә буларак, авыл мәктәбен тәмамлаган балалар да русча әйбәт кенә сөйләшә-аңлаша алырлык булып чыга. Бу - беренчедән. Икенчедән, татар телен - үз теләңне шәп белгән хәлдә, рус телен дә камил өйрәнергә кирәк, дигән фикер әйтелергә тиеш бит! 1917 елгы революциягә кадәрге татар мәдрәсәләреннән өчәр-дүртәр тел белеп чыгу гадәти хәл булган ләбаса!

Бу нисбәттән гаилә тәрбиясенә аерым тукталасым килә. Укыткан укучыларым арасында зур дәрәҗәләргә ирешеп килүчеләр бар. Нинди генә һөнәр иясе булсалар да, алар театр-концертларга йөри, әдәбиятны белә һәм укый, зур шәһәрләрдә яшәсәләр дә, сөйләмнәре дә саф татарча. Инде үз балаларында да шул сыйфатларны тәрбиялиләр.

Чаллыда яшәүче бертуган апамның улы рус мәктәбендә укыды, техник вузда белем алды. Татар әдәбияты, сәнгате белән кызыксына. 28 яшьлек егетнең бүген Нәбирә Гыйматдинова әсәрләрен көтеп алып укуына, А.Гыйләҗев, М.Мәһдиевләрне белеүенә соклanaсы гына кала.

Ана теленең югалмавы, өйрәтелүе өчен гаиләнең дә җаваплы булуы бәхәссез. Бу юнәлештә гаилә, балалар бакчасы, мәктәп, хакимият бергәләп эшләргә тиеш.

Әгәр дә бүген мәктәпләрдә туган телне укытуга сәгатьләр санын, радио, телевидениедә татарча тапшыруларга каралган вакытны кыскартсак, китапханәләрне япсак, күңелдәге бушлыкны һич нәрсә белән тутырып булмаячак. Бер сәбәпсезгә урамда йөрү, сәгатьләр буе компьютер каршында утыру, комарлы уеннар, телевидениедән күрсәтелә торган үтереш, сугыш турындагы кинолар, тиз генә акча эшләргә өйрәтә торган күңел ачу программалары кешене бик тиз рухи ярлыландыра, һәлакәткә алып бара. Уйланырлык әйберләр болар.

Кайберәүләрнең телгә мөнәсәбәте дә мине шаккатыра. Алар туган телне сакларга кирәклекне бик җиңел аңлый, әгәр дә теге яки бу кеше чит телләрне нығытып өйрәнә башласа яки шомарак сөйләшергә өйрәнү өчен кайбер вакытта русча аралаша башласа, бу үз телен оныткан, диләр. Әйтерсең, башка телне өйрәнсә, кеше үз телен оныта! Ә бит үз теленә хөрмәт, милләте белән горурлану хисе тәрбияләнгән булса, ул һәрвакыт башка милләт кешесенә үз халкы турында сөйли, аның белән горурлана. Моның өчен башка телләрне дә белергә кирәк. Күп телләр белгән кешедән куркырга кирәкми - алар чын зыялы шәхес булып формалаша. Ә менә үз милләте тарихын, гореф-гадәтләрен белмәгән надан-нардан куркырга кирәк.

***Ләйсән ӘМИНОВА,***
***Актаныш гимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

## Индус ТАҺИРОВ:

# "Һәр революциягә альтернатива бар"

**1 февраль көнне "Алтын урта" клубында тарих фәннәре докторы, профессор, Россиянең һәм Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Индус Таһиров белән очрашу үтте. Милли һәм дини сәясәт турында сөйләшү, президент сайлаулары алдыннан Россиянең киләчәген фаразлау, узган гасырның туксанынчы елларында булган килешүләрне искә төшерү… Гомумән, кичәдә актуаль сораулар күтәрелде.**



Яшьләр үзләре дә кызыксынып, Индус абыйга сораулар биреп, аның төрле мәсьәләләргә фикерләрен сорашып утырды.

Кичәнең иң үткен мизгелләре белән сезне дә таныштырып үтик.

Соңгы арада РФ Хөкүмәте рәисе В.Путинның берничә мәкаләсе чыкты. Шуның берсе милли мәсьәләләргә карый. И.Таһиров әлеге мәкаләне анализлап алды һәм милли мәсьәләнең нидән гыйбарәт булырга тиешлеге турында сөйләде.

Нәрсә соң ул милли мәсьәлә? Ул нидән гыйбәрәт?

1. Милләтләрнең исән-имин калуына гарантия булырга тиеш.

2. Милләтнең телен саклап калырга кирәк. Телсез милләт Россиядә руска әйләнә.

3. Дин. Әгәр динебез халыкка сеңмәгән булса, 1552 елдан соң татарлар юкка чыккан булыр иде. Дин телебезне дә саклады.

4. Гореф-гадәтләребез, йолаларыбыз.

5. Дәүләтебез. Төркиләр арасында татарлар иң борынгы дәүләти халык. Татарлар - заманында монголларны да бусындырган халык бит.

Шушы кыйммәтләр сакланса, милләтләр исән кала дигән сүз. Әгәр сәясәт милләтләрне саклыйбыз ди икән, менә шушы пунктларга җавап бирергә тиеш.

Индус әфәнде: "Путинның документын лакмус кәгазе белән чагыштырыр идем", - ди. Аның фикеренчә, милли мәсьәләргә кагылышлы мәкалә халыкның мөнәсәбәтен белер өчен язылган.

- Путин инде президент булыр, билгеле. Аңа лаеклы конкурентлар юк анда. Президент булгач, ул менә шушы халык фикерен ныклап өйрәнергә тиеш. Минем әйткәнем дә бар: "Әгәр син дәүләт президенты икән, үзеңне рус итеп кенә хис итмә. Татар итеп тә, башкорт итеп тә, чечен итеп тә хис ит. Чөнки син башкаларның мәнфәгатьләрен дә якларга тиеш".

Индус Таһиров дәүләтчелек турында да сөйләде. "Без бит 1917 елга кадәр рәсми рәвештә дәүләтле булган халык. Империя таркалу белән генә дәүләтсез калабыз. Бу халәт тә өч ел гына бара - 1920 елда суверенитет кабул ителә", - ди ул.

XX йөзнең 90 нчы еллары, Мәскәү белән сөйләшүләр алып бару турында да тема күтәрелде. Индус Таһиров - Россия белән сөйләшүләр алып бару делегациясенең җитәкче урынбасары булган кеше дә бит.

- 1992 елны 4 августта Кремльдә булдык. Вице-президент, Россия белән сөйләшүләр буенча делегация җитәкчсесе Лихачев, мин аның урынбасары идем. Россиянең делегация җитәкчесе, Ельциннан соң икенче кеше - Г.Э.Бурбулис белән очраштык. Ул безгә: "За год переговоров с Татарстаном мы очень сильно изменились. И сейчас считаем, что Россия должна быть ассимметричной федерацией с элементами конфедерации", - дигән иде. Бу - төрле хокуклы ил дигән сүз. Мисал өчен, Чувашстанга караганда, Татарстанга күбрәк хокуклар кирәк. Кайберәүләргә акча да җитә, хокуклар кирәкми. Ә без үз көнебезне үзебез күрә ала торган халык. Безнең мөмкинлекләребезне бумасалар, башкалар өчен дә үрнәк дәүләт төзи алабыз.

Россия Президенты бу елны Тарих елы дип, ә Татарстанныкы - Тарихи-мәдәни мирас елы дип игълан итте. Индус Таһиров фикеренчә, болардан файдаланып калырга кирәк. Путинның документын ул "саран вәгъдәләр документы" дип атый. "Шулай булса да, безнең таләпләрне үтәү өчен анда нигез бар", - ди Индус әфәнде.

Якынлашып килүче сайлаулар, Путинның унике ел рәттән президентлык итү мөмкинлеге - актуаль сораулар. Индус Таһиров бу мәсьәләдә дә үз фикере белән уртаклашты.

- Путинның 12 ел утырачагына бик шикләнеп карыйм. Чөнки аның беренче срогында ук зур үзгәрешләр булачак… Әйтик, Думага сайлау була. Аның нәтиҗәләре инде бүгенге кебек булмый, башкача булачак. "Единая Россия" партиясе эреп юкка чыгарга мөмкин. Шуннан соң Путин икенче срокка кала аламы? Әллә властька икенче кешеләр киләчәкме? Әлбәттә, ул кешеләр Жириновский да, Зюганов та, Миронов та түгел. Болар бит уйналган карталар гына, алар кәмит уйный. Нигездә, барысы да Путин ягында, аның президент булып сайлануы ягында. Тәнкыйтьләгән булалар да, шуның белән эшләре бетә, берни өчен җавап бирәсе түгел. Киләчәктә башка оппозиция барлыкка киләчәк. Бәлки ул, әнә, урам хәрәкәте булыр. Урамда бит хәзер хәерчеләр юк. Хәзерге революцияләр элекке заманадагы кебек җир мәсьәләсенә төртелми. Хәзер байлар революциясе китте.

Кичәдә Башкортстан турында да сүз булды. Рәхимов белән Шәймиевнең 1990 нчы еллардагы аралашуы, милли мәсьәләләр, ике халык арасындагы мөнәсәбәт… Индус Таһиров башкортларның һәм татарларның телләре бер үк, дип әйтте. "Әгәр Уфа үзәгенә барып татар халык җырын башлап җибәрсәң, сиңа дәррәү башкалар да кушылачак", - ди ул. Башкортстанның татар авылларындагы кешеләрнең бер колагына килеп: "Син кем?" дип сорасаң, "татар", дип, икенче колагыннан сорасаң, "башкорт", дип җавап бирәчәкләр дип, көлдереп тә алды.

Мөселман яшьләре Индус әфәнденең киләчәккә фаразларын да белергә теләде. Ул, җитди һәм ягымлы, тыныч тонда сөйләвен түбәндәге сүзләр белән тәмамлады:

- Киләчәк буын динебезгә күнгән, гореф-гадәтләребезне саклаучан, телебезгә, халкыбызга тугры рәвештә үсә икән, киләчәгебез, һичшикесез, якты булачак. Җиңел юллар гына дип әйтмим. Россиянең әле күрәчәкләре бар. Алардан исән-имин, мөселман буларак чыгуны яшьләр тәэмин итә. Россиядә революция булуы өчен бөтен объектив шартлар бар. Революциягә җиткермисе иде. Чөнки һәр революциягә альтернатива бар. Халык фикерен тыңлап, демократиягә юл ачу, Россиянең федератив, ассимметрияле булуын тормышка ашырып яшәлсә, афәтләрдән котылып чыгачакбыз...

# Стрессмы, иман тынычлыгымы?

***"Би-би-си"га һәм "Голос Америки"га ышансак, Европадагы 164 миллионнан артык кешенең психикасы чирле икән. Бу Европаның утыз илендә яшәүчеләрнең 38 проценты нервлар какшавыннан алып шизофрениягә кадәр диапазондагы чирләр белән интегә дигән сүз.***



Мәгълүмат ташкыны астында калган хәзерге ашкын җәмгыятьтә күңел төшенкелегенең ни икәнлеген татып карамаган инсанны табуы кыен. Депрессия исә баш миен генә зарарлап калмый, иммунитетны җимерә, тәндәге барлык әгъзаларны сафтан чыгара. Бу - хәзерге медицина тарафыннан инде расланган факт. Әйтик, табиблык фәнендә психоиммунология тармагы иң яшь юнәлеш булып саналса да, нәтиҗәләре ышанычлы дәлилләнгән: күңел тынычсызлыгы организмны акрынлап тар-мар итә, бәндәне инвалидлыкка чыгара, кайбер аеруча кискен очракларда хәтта кабергә дә китереп тыга. Баш миен өйрәнүче Көнбатыш белгечләре исәпләп чыгарган: стресска бәйле чирләрне дәвалау өчен, Европа гына да ел саен бер триллион доллар акча сарыф итәргә мәҗбүр. Гигант сумма бу, әмма аңа әле стресс нәтиҗәсендә зарарланган ашказаны, бавыр, бөер, простата кебек әгъзаларны дәвалау чыгымнары кермәгән.

Рәсми медицина күңел төшенкелегеннән барлыкка килгән чирләрне соңгы утыз елда гына ныклап өйрәнә башласа, ахырзаман пәйгамбәре Мөхәммәд (сгв) инде мең биш йөз елга якын элек үк: "Белегез: тәндә бер ит кисәге бар, әгәр ул ит кисәге төзәлсә, бөтен тән төзәлер, әгәр ул ит кисәге бозылса, бөтен тән бозылыр. Ул ит кисәге - йөрәктер", - дип белдерде, ягъни төрле әгъзалардагы чирләрнең күңелдәге уйлар, калебтәге хисләр нәтиҗәсе икәнен аңлатты. Онкологик чирләрне дәвалаучы Америка табибы Берни Сигл: "Рух сәламәтлеге - тән сәламәтлеге", - дип игълан итте һәм шул исемдәге китап язып бастырды. "Сәламәт тәндә - сәламәт акыл" дигән әйтемне киресенә әйләндерде.

Югарыда китерелгән саннар материалистик җәмгыятьнең даими депрессия хәлендә булуы, стресс кичереп яшәве турында сөйли. Бу - Аллаһны онытканнар өчен котылгысыз халәт. Аллаһы Тәгалә Үзе бу хакта Коръәннең 103 нче "Гасыр" сүрәсенең 2-3 нче аятендә ачык итеп аңлата (тәфсир): "...Дөреслектә, адәм баласы хәсрәттәдер, кадерле гомерен дөнья өчен генә әрәм итеп зур зарарланудадыр. Мәгәр Коръән өйрәткәнчә, дөрес юл белән чын иман китереп, Ислам динен кабул иткән, һәрвакыт изге гамәлләр кылган, Коръән дәлилләре белән, хактан һич тә аерылмаска бер-берсен өндәшкән һәм тормыш, дин мәшәкатьләренә, килгән төрле авырлыкларга, бәла-казаларга сабыр итәргә, чыдамлы булырга бер-берсен өндәшкән хак мөэминнәр генә зарарлануда, кимчелектә, хәсрәттә булмаслар". (Ногмани тәфсиреннән)

Күңел төшенкелегенең чыганагын һәм депрессиядән котылуның универсаль ысулларын аңлата адәм баласына бу сүрәдә Аллаһы Тәгалә. Стрессның төп нигезе - материализм, бу дөньяга табынып, аны бар итүчене кире кагу яисә оныту. Депрессиядән котылуның төп ысулы - Коръән өйрәткән юл белән яшәү, изге гамәлләр кылу, мөэминнәрнең бер-берсен авырлыкларга чыдам булырга өндәүләре.

Мәскәүдә Инна Шот дигән редактор бар, ул балалар өчен журнал чыгара. Күреп таныш булмасак та, Facebook.com сайты аша аның белән еш аралашабыз. Инна минем рус телендә язганнарымны укый һәм ошатуын белдерә, аның фәлсәфи фикерләре миндә дә бик еш теләктәшлек таба. Бу табигый, чөнки Инна - мөслимә хатын. Тормыш авырлыклары тудырган хәсрәт тойгысыннан котылу юллары турында да еш искәртә ул. Күптән түгел генә диварына "Күк күкрәү" сүрәсеннән йөрәкләрнең бары тик Аллаһы Тәгаләне искә төшергәндә генә тынычлык табулары турындагы аятьнең тәфсирен язып куйган иде. Гомумән, сабырлык, проблема килеп туганда ярдәм сорап Хак Тәгаләгә мөрәҗәгать итү турында Инна еш яза һәм язганнарын рухи кардәшләренә юллый. Мөэминнәрнең нәкъ менә шул рәвешле бер-берсен үгетләүләре, өндәүләре хәсрәттән котылуның бер юлы икәнлеген искәртә бит Аллаһы Тәгалә дә "Гасыр" сүрәсендә.

Күңел төшенкелегеннән котылу өчен аның табигатен, нилектән килеп чыгуын өйрәнү мөһим. Мин үзем стрессның өч төп сәбәбен аерып чыгарам. Беренчесе - киләчәк өчен курку, үз алдында торган проблеманы хәл итә алмам дип гаҗизләнү. Без еш кына таза-сау һәм кулыннан эш килә торган кешеләрнең иртәгесе көнгә ышаныч юк дип зарлануларына юлыгабыз. Бу зарлану артында эшсез калырмын, малсыз калырмын, ризыксыз калырмын дигән курку ята. Шул курку хәсрәткә сала адәм баласын, стресс кичерергә мәҗбүр итә. Ярты гомерен шул хәсрәт белән үткәргәннәргә мөрәҗәгать итеп, бер нәрсәне искәртер идем. Хәсрәтегезнең кысыр хәсрәт икәнен аңлау өчен, артыгызга борылып карагыз: үткән гомерегездә күпме булды андый куркулар, барысы да үтте, ризыгыгыз киселмәде, үзегез үлмәдегез. Киләчәктә дә нәкъ шулай булачак: әҗәлегез җитмәсә, ризыгыгыз киселмәс. Бу дөньядагы проблемаларның барысы да - үтүче проблемалар. Күңел төшенкелеге алда торган киртәне үтәргә булышмый, эшне кыенлаштыра гына. Ә инде ризык һәм мал мәсьәләсенә килсәк, Аллаһы Тәгалә Коръәндә аларның үзеннән икәнен ачык итеп аңлата һәм һәртөрле тереклек иясен ризыкландырырга вәгъдә бирә. Шушы вәгъдәгә иман китерү адәм баласын иртәгесе көн өчен хәсрәт утында булудан коткара. Иман китермәгәннәр өчен исә чара юк, алар даими стресста булачаклар. Әгәр дә инде үзен мөселман дип атаучы да, иртәгесе көн өчен кайгырып, күңел төшенкелеге кичерә икән, иманын тикшерсен, димәк, иманда кимчелек бар. Бу кимчелек ике төрле сәбәптән булырга мөмкин: беренчесе - белем җитмәү, икенчесе - монафыйклык (икейөзлелек). Ризык (мал) проблемасын аңлауда ислам дине кешеләрне бишкә бүлә. Бу урында мин шуларның икесен генә китереп үтәм. Берәүләр ризыкны Аллаһы Тәгаләдән дип белә, ләкин бирәме-юкмы икәнен белми, болар - шик кылучы монафыйклар. Ризык хәсрәте боларны да читләтеп үтмәячәк. Икенчеләре ризыкны (малны) Аллаһтан дип белә һәм кәсеп итүне ризыкның сәбәбе дип таный һәм, сәбәп дөньясында яшәгәнлектән, ризык табу юлында тырышлык күрсәтә, Аллаһның вәгъдәсенә берсүзсез ышана. Болары - мөселманнар. Менә шулар кальбендә күңел тынычлыгы хакимлек итә дә инде. Тулы тынычлыкка ирешү өчен, мондыйларга ризыкның хакын чыгару, ягъни зәкят һәм гошер түләү генә кирәк.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# "ИЗГЕ ВӘЛИ" КӨНЕ, ЯКИ ГАДИ ФӘҺРИКАМАЛ ДӘГЪВАСЫ

**Мәктәптән кайтканнан бирле, Илгизәр борын астыннан гына ниндидер сәер, моңарчы ишетелмәгән җырны көйләп йөри: "Валентин, Валентин, изге Валентин..." Бу аңлашылмаган җырның сәерлегенә исе китеп, әбисе Фәһрикамал оныгына сүз катты:**

- Балакаем, нәмәстәкәй көйләп йөрисең соң син? Нинди Валентин бу тагын?

- Әй, шуны да белмисең инде, әби! - дип горурлану катыш шатлык хисләрен йөзендә балкытып җавап бирде Илгизәр. - Иртәгә - изге Валентин көне, ягъни барлык гашыйк булганнарның бәйрәме!

- Гашыйк булганнар көне?..

Җиденче сыйныфта укучы оныгының шушы сүзләреннән хәйран калып, Фәһрикамал апа аптырап диванга утырды.

- Менә сиңа мә-ә... Гашыйклар көне... Уникe яшьтәме?!

Соңгы ике сүзе йөрәгенә кадалган ике уктан да үткенрәк тоелып, әбекәйне сискәнеп куярга мәҗбүр итте. Шулай да үзен кулга алырга тырышып, Фәһрикамал апа сорау алуын дәвам итәргә булды.

- Ә Валентин дигәннәре кем була инде ул? Әле җитмәсә изге дә икән үзе.

- Бу изге абыйның кем икәнлеген мин белмим, ләкин иртәгә бәйрәм шәп булачак, әби. Без анда концерт куябыз. Миңа да бер җыр башкарасы була.

- Нинди җыр инде ул, улым?

- Александр Серовның "Я люблю тебя до слез" дигән җыры! - диде горур кыяфәт белән Илгизәр. - Без аны Фирүзә Ибраһимова белән җырлыйбыз, ә Сәрия апа пианинода уйный. Ярый, әби, мин классташым Шамил янына киттем, безнең әле "валентинкалар" тутырылмаган. Пока!

Илгизәрнең кычкырып, күтәренке күңел белән әйтелгән шушы сүзләре Фәһрикамал апаның йөрәгенә әүвәл кадалган ике укка автоматтан атылган пулялар кебек өстәлде диярсең. Кан басымы күтәрелгәнлектән күз аллары караңгыланган булса да, әбисе чыраен сытып, авызыннан берничә сүз кысып чыгара алды:

- Тукта, тукта... Ай-й-йөрәгем, абау! Улым, зинһар, әйт: кем тутырылмаган? Нинди Валялар ул тагын? Кая барасың син?!

- Үзең син Валя! Валя түгел, ә "валентинка". Ул шушы изге Валентин көненә чыгарылган матур открытка. Малайлар кызларга, кызлар малайларга мәхәббәт белдереп, аларны язып тутыралар һәм яраткан кешеләренә тапшыралар. Аңладыңмы инде хәзер?

- Аңладым, балакаем, аңладым. Әллә яраткан кызың да бармы?

- Яратасыңмы-яратмыйсыңмы, сыйныф җитәкчебез язарга кушты. Өчтән дә кимрәк булмасын, диде. Так што, эшебез җитәрлек бүген безнең, сәгать җиделәрсез кайтып булмас. Ярый, киттем, әби!

* * *

Фәһрикамал апа үзен начар хис итте. Җитмәсә, мәчет каршындагы мәдрәсәнең кечке бүлегендә укучы кызы Гөлиянең бүген уку көне, унынчы яртысыз кайтмас. Икенче гаилә корып җибәргән элекке кияве исә малаеның хәле белән кызыксынмый, аны бөтенләй кайгыртмый диярлек, шуңа ул киңәшче һәм таяныч түгел. Ә Гөлиягә, һичшиксез, бу хәлне сөйләргә, аның белән бергә киңәшләшергә кирәк.

Шулай уйланып утыра торгач, әби күзләрен йомып яшьлеген искә төшерде. Әйе, ул да заманында яшь, чибәр кыз иде. Әмма яшь чакта да урамга яулыксыз чыкканы булмады аның. Шуңадыр да авылның җилбәзәк, холыксыз егетләре аңа әллә ни игътибар итмәделәр, артык тыйнак кыз белән аларга, күрәсең, кызык булмагандыр. Ә менә үзе кебек тыныч холыклы, тыйнак һәм тәүфыйклы Гайнетдин аны читтән генә күзәтеп, ошатып йөргән, яраткан... Армиягә киткәнчегә кадәр дәшәргә оялган икән, бөркеткәй. Китәр алдыннан гына кыяр-кыймас: "Мин сиңа хат язый әле", - дип рөхсәт сораган. Хатларның дүртенчесендәме-бишенчесендәме генә сагынганын һәм өзелеп яратканын хәбәр иткән. Әй, гомер-гомерләр...




Җилбәзәк егетләргә кияүгә чыккан кызларның тормышлары рәтле булмады, ә Гайнетдин белән Фәһрикамал башкаларны көнләштерерлек итеп бик тату, матур тордылар, балалары да тәртипле булды. Гомер буе бер-берсен сөйделәр, хөрмәт иттеләр. Иренең вафатына инде тугыз ел булса да, Фәһрикамал апа аны һаман сагына, әле дә ярата. Аны гына. Гомергә.

Тормыш китабы сәхифәләрен шулай тиз-тиз әйләндереп алган арада Фәһрикамал апа нигәдер заманында авылдаш кызлары еш җырлаган бер җырны исенә төшерде:

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# БАРАК ОБАМАНЫҢ ӘБИСЕН АЛЛАҺ САКЛАДЫ

**АКШ президентының үги әбисе Сара Обама Кениядә яши. Аңа 91 яшь. Күптән түгел генә ул юл һәлакәтенә очрап, хастаханәгә эләкте, дип хәбәр итә "Франс Пресс" агентлыгы.**



Юл һәлакәтенә Сара Обама илнең көнбатышында урнашкан Кисуму шәһәреннән үзе яшәгән Когело авылына кайтып килгәндә юлыга. Америка президентының әбисе утырган машинаның шофёры, алда баручы йөк машинасын узып китәргә маташканда идарәне югалта һәм машина юлдан төшеп китә.

Машинада баручы Сара Обама һәм тагын дүрт пассажир тән җәрәхәтләре белән хастаханәгә озатыла.

Сара Обама шок хәлендә була, ләкин аның бәрелгән урыннары күп булмау һәм сәламәтлегенә зур зыян килмәгән булу сәбәпле, ул ике сәгатьтән соң хастаханәдән чыгарыла.

"Мине Аллаһы Тәгалә саклады. Без исән-сау килеш чыккан машинаның нинди хәлдә булуын күрсәгез икән! Бу гаҗәп хәл! - ди Сара Обама. - Күрәсезме: минем кулда кечкенә генә җөй һәм мин таякка таянмыйча гына да йөри алам.

Сара - Америка президентының кан туганы түгел: ул аның бабасының икенче хатыны. Шуңа карамастан, Барак Обама аны бик нык хөрмәт итә һәм аңа "Сара әби" дип эндәшә. 1995 елда дөнья күргән "Әтием хыяллары" дип аталган китабында ул аның белән 1988 елда Кениядә очрашуы турында яза.

Исегезгә төшерәбез: Сара Обама 2010 елда хаҗ гыйбадәтен үти. Хаҗда чагында ул оныгы (Барак Обама) ислам дине кабул итүен теләп дога кыла. Бу хакта Согуд Гарәбстанында нәшер ителә торган "Әл-Ватан" гәҗитенә сылтама биреп, "Франс Пресс" агентлыгы хәбәр итә.

Хаҗга исә Сара әби улы Сәед Хөсәен Обама һәм үзенең дүрт оныгы белән бара. Согуд Гарәбстаны хакимияте Обама гаиләсенең тору уңайлылыкларын тәэмин итүне үз өстенә ала. Обаманың абыйсы Согуд Гарәбстаны короле Габдулла ибне Габделгазизгә кунакчыллык, сый-хөрмәт күрсәткәннәре өчен үз рәхмәтен белдерә.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: сайлау кампаниясе барышында Б.Обама яшерен рәвештә ислам динен тота дигән имеш-мимешләр таралган иде. 2010 елның августында үткәрелгән җәмәгатьчелек фикерен сораштырулардан күренгәнчә, Америкада яшәүче һәр бишенче кеше Обаманы мөселман кебек күрә. Шулай да, Ак йорт президентның ислам динен яшерен рәвештә тотуы турындагы хәбәрне кире кага һәм аның "тәкъва христиан" булуын белдерә.

# Стрессмы, иман тынычлыгымы?

(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)

Стресснын икенче зур сәбәбе - көнчелек. Көнчелекнең ни икәнен аңлатып тору кирәк микән? Үзенә карата башкаларның көнчелеген тоймаган кешене табу кыен, аннан да бигрәк үз кальбендә бүтәннәргә карата көнчелек хисе уянмаган бәндәне табу катлаулырак. Әмма хөсетлек - тыелган сыйфат. Пәйгамбәребез (сгв) әйтә: "Кинә белән көнчелек изгелекләрне ут утынны ашаган кебек ашыйлар", - ди. Бәс, шулай булгач, мөэмин кешегә калебтәге бу хисне авызлыклау тиешле. Шуңа ирешә алмыйсың икән, стресс котылгысыз. Көнләшкән өчен адәм баласы биш төрле җәза ала. Беренчесе - киселми торган кайгы, ягъни даими стресс. Икенчесе - хәсрәте өчен әҗернең булмавы, ягъни стресс нәтиҗәсендә кичергән авырлыкның савап бирмәве. Өченчесе - хурлыкка калу, дүртенчесе - Аллаһы Тәгаләнең ачуына дучар булу, бишенчесе - бу кеше өчен тәүфыйк ишекләренең бикләнүе.

Адәм баласын депрессиягә китерә торган өченче сәбәп - бирелгәнгә риза булмау, шөкер итмәү. Өр-яңа өй салып чыккан, эш урынына ия, дүрт саны да сау-сәламәт булган бер танышымның мал кимлегеннән, хезмәт хакының азлыгыннан, байларның бай булуыннан даими зарлануыннан туйгач, мин аңа бервакыт: "Рөхсәт ит, Аллаһы Тәгаләдән сиңа аяксыз-кулсызларга, йортсыз-җирсезләргә биргәнне бирүен сорап дога кылыйм", - дидем. Ул шунда кинәт сискәнеп китте, үз хәленең нигъмәт икәнен аңлап алды, тәүбә итте. Хәлебез авыр дип уйлаганда, бу дөньяда бездән күп тапкыр авыррак хәлдәге миллионнар бар икәнен искә төшерү, шөкер итеп, стресстан котылырга булыша. Шөкер итүче күңел стресс кичерми, бу - абсолют хакыйкать.

***Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ,***
***филология фәннәре кандидаты***

# ВЛАДИМИР ПУТИН дини конфессия вәкилләре белән очрашты

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

Премьер фикеренчә, Россия университетларында "теология" дип аталган специализация, ә "Дөньяви этика һәм дини мәдәният нигезләре" фәнен укыту өчен махсус әзерлекле мөгаллимнәр барлыкка килергә мөмкин. "Киләчәктә әлеге предметның формаль ликбезга әйләнмәве мөһим, шуңа күрә мондый дисциплиналарны укытуны, әлбәттә, яхшы әзерлеге булганнар - я теолог, я дин кешесе алып барырга тиеш. Һәм шуңа мөнәсәбәтле рәвештә, шулай ук дәүләтнең ярдәме кирәк булачак, мин моны яхшы аңлыйм", - диде хөкүмәт башлыгы.

Владимир Путин шулай ук мәктәпкәчә белем бирүгә дә аерым игътибар бирергә чакырды. Аның сүзләренә караганда, дини берләшмәләрнең яңа балалар бакчалары ачу омтылышы һәм гамәлдә булган мәктәпкәчә учреждениеләрдә мәгърифәтчелек эше белән шөгыльләнүе - дәүләт властенең барлык дәрәҗәләрендә дә яклау табарга тиеш.

Президентлыкка кандидат булучының сүзләренә караганда, дәүләт башка төрле ярдәм күрсәтергә дә әзер: мисал өчен, телеканалларда традицион диннәргә өстәмә эфир вакыты бүлеп бирү.

**Нияз САБИРҖАНОВ**

# КИКта – АЧЫК ДӘРЕС

***7 февраль көнне Казан ислам колледжында (КИК) Коръән тәфсире буенча ачык дәрес узды. Дәресне Җәләлетдин әс-Сөютинең "әл-Җәләләйни тәфсире" китабы буенча Камил хәзрәт Сәмигуллин алып барды. Дәреснең темасы Коръәни-Кәримнең 78 нче "Нәба (Хәбәр)" сүрәсенең 1-24 нче аятьләрен өйрәнүгә багышланды.***

Ачык дәресне "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе мөгаллимәсе Флёра абыстай Ханнанова, Ислам дине кабул ителүнең 1000 еллыгы исемендәге мәдрәсә укытучысы Илдар хәзрәт Ситдыйков, Кукмара мәдрәсәсе директоры Ришат хәзрәт Курамшин, Россия ислам университетының ислам фәннәре факультеты деканы Рамазан хәзрәт Курамшин, Казан ислам колледжы директоры урынбасары Нияз хәзрәт Сабиров, шулай ук ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең мәгариф һәм фән бүлеге мөдире Вәлиулла хәзрәт Якупов, шул ук бүлек белгече Айдар Карибуллин һәм мөфтиятнең яшьләр белән эшләү бүлеге белгече Нияз Сабирҗанов карады.

Чара тәмамланганнан соң, кунаклар тарафыннан ачык дәрес бәяләнде.

Нияз Сабирҗанов дәрес барышында җибәрелгән методик хаталарга күзәтү ясады. Нигездә, ул дәрес структурасына кагылышлы иде: ник дигәндә, дәрес этаплары түбәндәге эзлеклелекне югалтты: 1) дәресне оештыру; 2) актуальләштерү; 3) яңа белем һәм күнекмәләр бирү; 4) белем һәм күнекмәләрне ныгыту; 5) өй эше бирү; 6) йомгаклау. Шулай ук ул К.Сәмигуллин дәресенең уңай якларын да атады: мисал өчен, аудиторияне игътибар үзәгендә тота алу, укытучының үз предметын бик яхшы белүе һәм укытучының ораторлык сәләтенә ия булуы.

Үз фикерләрен шулай ук Кукмара мәдрәсәсе директоры Ришат хәзрәт Курамшин да җиткерде. Иң әүвәл, ул, мөгаллимнең тәфсир фәне өлкәсендә тирән белемнәргә һәм яхшы дикциягә ия булуына басым ясады. Алга таба дәреснең җитешсез яклары да санап узылды: студентлар белән ныклы диалог булмау һәм аларның өй эшләре тикшерелмәү. Шулай ук, дәрестә каралган сүрә аятьләренең файдалы яклары да тулысынча ачылмады, күрсәтмәлелек материаллары булмады һәм дәрес ахырында нәтиҗә ясалмады.

Методист һәм укытучы Флёра Ханнанова дәреснең һәм уңай, һәм кимчелекле якларын санап узды. Уңай моментларга ул дәрестә укытучының тәрбия бирү максатларына мөрәҗәгать итүен китерде. Ләкин әлеге максатның укучыларга тулысынча барып ирешмәвен дә искәртте ул. Сүрәләрдә очрый торган катлаулы сүзләрне аңлату өчен сүзлек белән эш алып барылмауга да басым ясады.

Ислам дине кабул ителүнең 1000 еллыгы исемендәге мәдрәсә укытучысы Илдар хәзрәт Ситдыйков ачык дәреснең башка ислам фәннәре белән дә бәйләнгән хәлдә алып барылуын һәм укытучының дәрес темасын ачу өчен җитди әзерләнгән, шулай ук мөгаллимнең тәфсир фәне өлкәсендә зур белемнәргә ия булуын билгеләп узды.

Әңгәмә барышында Камил хәзрәт Сәмигуллин үз коллегаларының фикерләрен йотлыгып тыңлады һәм киләчәктә дә педагогик эшчәнлектә хезмәттәшлек итәргә вәгъдә бирде. Шулай ук, ул чарада катнашучыларга рәхмәтен җиткерде.

ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең мәгариф һәм фән бүлеге мөдире Вәлиулла хәзрәт Якупов, мондый төрдәге ачык дәресләр үткәрү мөгаллимнәр арасында тәҗрибә алышуга җирлек тудыра, дип нәтиҗә ясады. Ул ачык дәресләрне рәсми рухи мәгариф учреждениеләре (мәдрәсәләр) булган республикабыз районнарында да оештыру тәкъдиме белән чыкты.

**Айдар КАРИБУЛЛИН**

# "ИЗГЕ ВӘЛИ" КӨНЕ, ЯКИ ГАДИ ФӘҺРИКАМАЛ ДӘГЪВАСЫ

**(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)**

*Урманнарда йөрдем бер ялгызым,*
*Баласын җуйган болан эзеннән.*
*Башларым әйләнеп китте кинәт*
*Башканы сөям дигән сүзеңнән...*

Шушы дүртьюллыкны көйләп бетерүгә, оныгы Илгизәрнең сыйныф җитәкчесе заданиесе - "өчтән дә ким булмасын!" дигән сүзләре башка чүкеч кебек бертуктаусыз "суккалый" башлады: "...ким булмасын! Булмасын! Булмасын!!" Әстәгъфируллаһ, ничек инде берьюлы өч-дүрт кызга мәхәббәтеңне аңлатып открытка язарга кирәк? Гаҗә-әп... Шундый шәхси, һәркемнең үз сере булып саналган хисне укытучы кушуы буенча кемгәдер белдерү исә тагын да гаҗәбрәк тоелды Фәһрикамал апага.

Ишек ачылган тавыш ишетелде. Аллаһның рәхмәте, менә, ниһаять, Гөлия дә укудан кайтып җитте. Үз бүлмәсендә китап укып яткан Илгизәргә сиздермичә генә, Фәһрикамал апа көндез ишеткәннәрен кызына сөйләп бирде. Кәефе киткән Гөлия башта улына дәшмәкче булды, әмма төнгә каршы борчымыйм дип, кире уйлады:

- Иртәгә эштән иртәрәк китеп, мәктәпкә кереп чыкмыйча булмас. Аңлатып карасыннар укытучылар шул билгесез, берьюлы өч кешегә "до слез" гашыйк булырга өйрәтә торган Валентинның "изгелеген"! Аңлатып карасыннар!

**(Ахыры киләсе саннарда.)**

*Ришат КУРАМШИН,*
*Кукмара мәдрәсәсе директоры*

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 11.02.12 | 6:48 | 8:18 | 13:02 | 16:06 | 17:38 | 19:08 |
| Якшәмбе | 12.02.12 | 6:46 | 8:16 | 13:02 | 16:07 | 17:40 | 19:10 |
| Дүшәмбе | 13.02.12 | 6:44 | 8:14 | 13:02 | 16:09 | 17:42 | 19:12 |
| Сишәмбе | 14.02.12 | 6:42 | 8:12 | 13:02 | 16:10 | 17:44 | 19:14 |
| Чәршәмбе | 15.02.12 | 6:40 | 8:10 | 13:02 | 16:12 | 17:47 | 19:17 |
| Пәнҗешәмбе | 16.02.12 | 6:37 | 8:07 | 13:02 | 16:13 | 17:49 | 19:19 |
| Җомга | 17.02.12 | 6:35 | 8:05 | 13:02 | 16:15 | 17:51 | 19:21 |
| Шимбә | 18.02.12 | 6:33 | 8:03 | 13:02 | 16:16 | 17:53 | 19:23 |

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №6 (123) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-526.

**Газета бушлай таратыла.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 9 февраль көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан саклангыз!**